КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 29 декабрь г.Казань № 1193

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау системасының медицина оешмалары тарафыннан донорлар канын һәм аның компонентларын хәзерләү, саклау, транспортта күчерү һәм аның куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча дәүләт эшен башкаруга норматив чыгымнарны раслау турында» 2024 ел, 9 сентябрь, 748 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау системасының медицина оешмалары тарафыннан донорлар канын һәм аның компонентларын хәзерләү, саклау, транспортта күчерү һәм аның куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча дәүләт эшен башкаруга норматив чыгымнарны раслау турында» 2024 ел, 9 сентябрь, 748 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 ел, 29 август, 647 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау системасының медицина оешмалары тарафыннан донорлар канын һәм аның компонентларын хәзерләү, саклау, транспортта күчерү һәм аның куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча дәүләт эшен башкаруга норматив чыгымнарга карата төзәтү коэффициентларының «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика кан үзәге» дәүләт

автоном сәламәтлек саклау учреждениесе» юлындагы 2 графасында «1,138770» саннарын «1,104243» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына донорлар каныннан һәм аның компонентларын хәзерләү, саклау, транспортта күчерү һәм аның куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау системасының медицина оешмалары башкара торган дәүләт эше күләмнәрендә:

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика кан үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе» бүлегендә:

«кан донорларыннан компонентларга аертылмаган донорлар каны» юлының 5 графасында «20 394,7» саннарын «25 358,01» саннарына алмаштырырга;

«автоматик аферез ысулы белән компонентларга аертылмаган донорлар каны (плазмаферез ысулы белән яңа туңдырылган плазма хәзерләү өчен)» юлының 5 графасында «12 166,4» саннарын «4 191,44» саннарына алмаштырырга;

«тромбоцитоферез ысулы белән компонентларга аертылмаган донорлар каны (плазмаферез ысулы белән яңа туңдырылган плазма хәзерләү өчен)» юлының 5 графасында «4 962,5» саннарын «10 869,37» саннарына алмаштырырга.

2. Бу карар 2025 елның 31 декабренә кадәр (31 декабрьне кертеп) гамәлдә була дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин